**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **29.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Бирючевка авыл җирлеге составына керүче,
Бирючевка авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 150 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- юлларга асфальт җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Мира ур.,Бирючевка авылы; Молодежная ур., Бирючевка авылы;
-Авыл халкына бәйрәмнәрне оештыру өчен: “Сабантуй”,”Картлар көне”,”Яна ел” бәйрәмнәре өчен;

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бирючевка авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Нуреева